СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2019 елның 23 октябре № 38/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 72 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 пунктының 26 пунктчасы, «дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Чүпрәле районы прокуроры протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2016 елның 14 сентябрендәге 11/4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1)** 2 өлештә**:**

а) 6 пунктның 3 пунктчасында, 14-16 пунктларда«, физик зат (граждан)» сүзләрен тиешле килешләрдә төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 20.1 пунктын өстәргә:

«20.1. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль җир инспекторы тарафыннан мондый объектны җир кишәрлегеннән файдалану рөхсәт ителгән һәм (яки) җир кишәрлекләреннән файдалану буенча билгеләнгән чикләүләр нигезендә урнаштыру рөхсәт ителми торган җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектын урнаштыру факты ачыкланган очракта, әлеге зат тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге җир участогы урнашкан урын буенча авыл җирлеге җирле үзидарә органына яисә бу җир кишәрлеге авылара территориядә урнашкан очракта, муниципаль районның җирле үзидарә органына үз белдеге белән

төзелгән корылманы ачыклау турында хәбәрнамә җибәрә. Үзирекле корылманы ачыклау турында хәбәрнамәнең рәвеше, шулай ук үз белдеге белән төзелгәнлек билгеләренең булуын раслаучы документлар исемлеге шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнә. Күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча җир кишәрлегенең хуҗасы тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин».

**2)** 3 өлешнең 2 пунктында «җир законнарын бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров